**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Буа районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Буа районының Карлы авылындагы Муса Җәлил урамы 38А бинасында урнашкан «Хәйруллов Мөдәррис Мөнир улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә өч ай дәвамында барлык кош-корт асраучыларга башка хуҗалыкларга яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Буа районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2020 елның 13 октябрендәге ПУ-686 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты**

**Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 07 ноябрь
№ ПУ-733